РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423752, село Чалманарат,
ул. Центральная,дом 2,
Тел. 3-44-64

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧАЛМАНАРАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

4235252, Чалманарат авылы,
Үзәк ур., 2 нчы йорт. Тел.3-44-64

# РЕШЕНИЕ

18 декабрь 2021 г. № 22

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чалманарат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 14 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Чалманарат авылы, Узэк урамы, 2 нче йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Тубэн Гэрэй авылы, Киров урамы, 18 нче йорт;, Чалманарат авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чалманарат авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чалманарат авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе К.С.Ахметов

Совет Чалманаратского сельского Поселения